СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Большой Битаман, ул. Московская, 2В

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В

Тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18 июль, 2022 ел** **№ 49**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2020 елның 06 августындагы 179 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 19.01.2021 N19 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрь 33 номерлы ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрь 33 номерлы ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 октябрь 10:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы Олы Битаман авылы, Мәскәү урамы, 2В йортында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2020 елның 06 августындагы 176 номерлы карары белән кабул

ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 19.01.2021 N19 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары Г.Н.Ибрагимова